ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 10 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 10 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1, № 9 (II өлеш); 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10 статьяда:
а) 1 өлештә «(башка төр дәүләт хезмәте)» сүзләрен төшереп калдырырга;
б) 5 өлешнең сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Дәүләт хезмәте стажын билгеләгәндә шулай ук тиешле вазыйфаи төркемнәрнең федераль дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларында, хәрби вазыйфаларда һәм хокук саклау хезмәте вазыйфаларында, дәүләт вазыйфаларында, муниципаль вазыйфаларда, тиешле вазыйфаи төркемнәрнең муниципаль хезмәт вазыйфаларында, федераль законнар нигезендә башка вазыйфаларда эш стажы исәпкә алына.»;

2) 17 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1. Үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы, шулай ук үз гаиләсе әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрне яллаучы вәкиленә түбәндәгеләр тапшыра:

1) дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүгә дәгъва итүче граждан – хезмәткә кергәндә;

2) Россия Федерациясе норматив хокукый актлары белән билгеләнгән исемлеккә кертелгән дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче дәүләт хезмәткәре – ел саен, хисап елыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2015 елның 2 июле
№ 55-ТРЗ